СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ГОРОД ИННОПОЛИС»
ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис,
Верхнеуслонский район, Республика
Татарстан, 420500

МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНЕҢ
«ИННОПОЛИС ШӘҺӘРЕ»
СОВЕТЫ
Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис
шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан
Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

РЕШЕНИЕ КАРАР

_____25.11.2021 ___3-28___________

№________________

"Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы карары проекты хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 83-85 статьялары, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең гамәлдәге Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында,

«Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы
Карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы Карары проектын хупларга, аны беренче укылышта кабул итәргә һәм, тәкъдимнәрне, төзәтмәләрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аның өстендә эшне дәвам итәргә (1 нче кушымта).
2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча килә торган тәкъдимнәрне кабул итү, исәпкә алу һәм карау буенча эшче төркем төзергә:

- Шагалиев Руслан Ринат улы-эшче төркем рәисе, Иннополис шәһәре Мэры;
- Афанасьева Вероника Валерьевна-эшче төркем секретаре, Иннополис шәһәре Башкарма комитетының хокукый ярдәм бүлеге башлыгы;

Эшче төркем әгъзалары:

Вандюков Дмитрий Владимирович - 1 нче күпмандатлы сайлау округы буенча «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы депутаты;
Сменихин Кирилл Владимирович - «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы депутаты, 1 нче номерлы күп мандатлы сайлау округы;
Яһудин Гадел Наил улы - «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы депутаты.

3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектына гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен расларга (2нче кушымта).

4. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен расларга (3 нче кушымта).

5. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча халык алдында тыңлауларны 2021 елның 8 декабрендә 12.00 сәгатьтә Иннополис шәһәре Башкарма комитетында: Иннополис шәһәре, Спорт урамы, 114 йорт, 1076 бүлмәдә уздырырга.

6. Эшче төркемгә Иннополис шәһәрендә яшәүчеләрнең тәкъдимнәрен гомумиләштерергә һәм аларны «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы каравына кертергә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Интернет челтәрендә Югары Ослан муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru) урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Рәислек итүче,
Иннополис шәһәре Мэры Р. Р. Шагалиев